# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Студеный Ключ авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

28 ноябрь, 2024 ел

№3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Студеный Ключ авылында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. 2025 елда Кукмара муниципаль районының Урта Комар авыл җирлеге Студеный Ключ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокл хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан; локаль сугышларда һәм Украинада махсус операция барышында һәлак булган гаиләләрдән; 80 яшькә житкән һәм аннан да өлкәнрәк затлардан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Студеный Ключ авылындагы чишмәләрне ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, култыксалы баскычлар урнаштыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Студеный Ключ авылы чишмәләрен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

2) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, ташуны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Студеный Ключ авылын су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре);

3) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Студеный Ключ авылына янгын гидрантлары сатып алу, ремонтлау һәм урнаштыру һәм янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү буенча башка эш төрләре)

4) традицион күмү урыннарын төзекләндерү, койма кору, ремонтлау (Студены Ключ авылында зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, материал саты алу һәм урнаштыру, коймаларны ремонтлау, инвентарь сатып алу, зира территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре;

5) торак пункт территориясен төзекләндерү

(спорт мәйданчыгын төзү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазлау, инвентарь җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Студеный Ключ авылын төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

6) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Студеный Ключ авылында урам-юл челтәрен карап тоту, юлларга вак таш салып төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, ягулык-майлау материаллары һәм МТЗ тракторына комплектлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Студеный Ключ авылында юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре);

7) тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Студеный Ключ авылында урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

8) урам яктыртуны рәтләү (Студеный Ключ авылында урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

9) яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру һәм Студеный Ключ авылының яр буе зоналарын, сулыкларын чистарту буенча башка эш төрләре)

10) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру Студеный Ключ авылының җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өстендәге кичүләрне ремонтлау буенча башка эш төрләре)

11) каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын төзү, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, каты көнкүреш калдыклары өчен

мәйданчыклар төзү һәм рөхсәтсез чүплекләрне бетерү буенча башка эшләрн гамәлгә ашыру)

12) тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру (килешу буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру Студеный Ключ авылының тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру буенча башка эш төрләре)

13) коеларны ясау, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, коеларны төзү, төзекләндерү һәм аларга якын территорияне төзекләндерү буенча башка төр эшләр).

3. Әлеге карарны Урта Комар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урта Комар авыл җирлеге башлыгы

ОГРН 1021607752891
ИНН 1623001660

С.В.Федоров